КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 23 май г.Казань № 480

2022 елда Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан бюджет акчасы белән баш эш итүчеләргә (эш итүчеләргә), бюджет акчасын алучыларга карата дәүләт финанс контролен гамәлгә ашыру үзенчәлекләре турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда бюджет акчасы белән баш эш итүчеләргә (эш итүчеләргә), бюджет акчасын алучыларга карата дәүләт (муниципаль) финанс контролен гамәлгә ашыру үзенчәлекләре турында» 2022 елның 14 апрелендәге 665 номерлы карары гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

2023 елның 1 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан дәүләт финанс контроле кысаларында бюджет акчасы белән баш эш итүчеләргә (эш итүчеләргә), бюджет акчасын алучыларга, шул исәптән дәүләт (муниципаль) заказчылары булганнарга карата тикшерүләр үткәрелми;

бюджет акчасы белән баш эш итүчеләрдән (эш итүчеләрдән), бюджет акчасын алучылардан, шул исәптән дәүләт (муниципаль) заказчылары булганнардан бу карар үз көченә кергәнгә кадәр бирелгән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тәкъдимнәрен (күрсәтмәләрен) үтәү срогын озайту турында мөрәҗәгатьләр кергәндә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган таләпләрне исәпкә алып, мондый мөрәҗәгатьләр кергән көннән 10 эш көне эчендә мондый мөрәҗәгатьләрне канәгатьләндерү турында карар кабул итә. Шул ук вакытта әлеге тәкъдимнәрне (күрсәтмәләрне) үтәү өчен яңадан билгеләнә торган срок 2023 елның 1 гыйнварыннан иртәрәк вакытка туры килә алмый;

бу карарның икенче абзацы Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты йөкләмәләре һәм Татарстан Республикасы прокуратурасы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең

Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы таләпләре нигезендә үткәрелә торган тикшерүләргә кагылмый;

бу карарның икенче абзацында күрсәтелгән, бу карар үз көченә кергәнгә кадәр башланган тикшерүләр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы карары белән 2023 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк булмаган вакытка кадәр туктатып торыла йә бу карар үз көченә кергән көннән 20 эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин